**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**МУНИЦИПАЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГАБИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422606 с. Габишево,
пр. Молодежный, д.1
тел: 4-46-57

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ГАБИШЕВО**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**
422606 Габишев авылы,
Яшьләр урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-46-57

**2026 елның «05» феврале** **2 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен расларга (1 кушымта).
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **М.Ф.Миндубаев**

2026 елның 05 февралендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшенең сыйфатын яхшырту, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын яхшырту максатларында уздырыла.

3. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау ел саен гамәлгә ашырыла.

4. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау барлык мөрәҗәгатьләр буенча да, шул исәптән язма рәвештә дә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү бүлмәсе аша электрон документ рәвешендәгеләр дә, шулай ук гражданнарны вәкаләтле затлар тарафыннан шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча да гамәлгә ашырыла.

5. Гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре хисап елыннан соңгы 15 гыйнварга кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә гражданнарны шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнарның саны, гражданнар шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турындагы мәгълүмат (булган очракта) булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тиешле чорда алдагы елның шушы чорына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән уздырыла (АППГ).

8. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча «Гражданнар

мөрәҗәгатьләре» бүлегендә ел саен хисап елыннан соңгы 15 гыйнварга кадәр аналитик белешмә урнаштыруны тәэмин итә.